**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү комиссиясе турында» Указына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү комиссиясе турында» 2016 елның 26 декабрендәге ПУ-1229 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 10 мартындагы ПУ-209 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 7 сентябрендәге ПУ-800 номерлы, 2018 елның 9 февралендәге ПУ-152 номерлы, 2018 елның 26 маендагы ПУ-392 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге ПУ-844 номерлы, 2019 елның 21 февралендәге ПУ-140 номерлы, 2019 елның 21 августындагы ПУ-478 номерлы, 2020 елның 18 февралендәге ПУ-100 номерлы, 2020 елның 4 мартындагы ПУ-136 номерлы һәм 2020 елның 12 декабрендәге ПУ-837 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү комиссиясе турында нигезләмәдә:

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Комиссия рәисе булмаганда яисә аның йөкләмәсе буенча Комиссия рәисе функцияләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

16 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комиссия рәисе булмаганда яисә аның йөкләмәсе нигезендә аның функцияләрен башкара;»;

б) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү комиссиясе (алга таба – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан О.Г. Синяшинны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

Айзатуллин Марат Мансур улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын;

Калачев Алексей Алексеевичны – «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры вазыйфаларын башкаручыны (килешү буенча);

Хәнифов Фәрит Мөдәррис улын – Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрын;

Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ш.Р. Агиевның – «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы» Берлеге рәисе (килешү буенча)»;

А.Н. Кудрявцеваның – «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 29 май
№ ПУ-412